| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» гыйнвар 2022 ел № 5

**Мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Кушымта нигезендә Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлегендә 6964,68 сум күләмендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү һәм гамәлгә кертү.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **В.А.Данилова**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районының
Зирекле авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 27 гыйнварындагы
5 номерлы карарына кушымта

**Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 997,28 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Барлыгы | 6964,68 |

**Мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 132,68 |
| 2. Мәетне киендерү (кәфенләү) | 1258,10 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2461,20 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1194,53 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1592,83 |
| Барлыгы | 6639,34 |